**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ИСКЕ АБДУЛ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

# КАРАР

«28» август 2019 ел Иске Абдул авылы № 15

**2019 елның беренче яртыеллыгы**
**өчен Тукай муниципаль районы Иске Абдул**
**авыл җирлеге бюджеты үтәлеше турында**
**хисап проекты буенча**
**халык тыңлауларын үткәрү хакында**

Тукай муниципаль районы Иске Абдул авыл җирлеге халкының «2019 елның беренче яртыеллыгы өчен Тукай муниципаль районы Иске Абдул авыл җирлеге бюджеты үтәлеше турында хисап» хакында карар проекты буенча фикер алышуда катнашу хокукларын саклау максатыннан, 1998 елның 31 июлендәге 145-ФЗ санлы Россия Федерациясе Бюджет кодексына, Тукай муниципаль районы Иске Абдул авыл җирлегендә халык тыңлауларын оештыру һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмәгә таянып

**КАРАР БИРӘМ:**

1. «2019 елның беренче яртыеллыгы өчен Тукай муниципаль районы Иске Абдул авыл җирлеге бюджеты үтәлеше турында хисап» хакында Тукай муниципаль районы Иске Абдул авыл җирлеге Советы карар проекты буенча халык тыңлауларын үткәрергә.

2. Әлеге Карарны 29 августында сонга калмыйча Тукай муниципаль районы рәсми порталында (www. tukay.tatarstan.ru/ ) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълумат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru),Иске Абдул авылы җирлеге бинасы янында җиһазландырылган мәгълүмат такталарында урнаштырырга.

3.Ачык тыңлауларны уздыру көнен билгеләү :

3.1. 2019 елның 06 сентябрь көнне,сәгать 14.30 уздыру;

3.2.Уздыру көне – 1 көн ;

3.3. Уткәрү урыны – ТР, Тукай муниципаль районы Иске Абдул авыл җирлеге, Үзәк урамы, 8 йорты (Иске Абдул авыл җирлеге Башкарма комитеты бинасы)

3.4.Сораулар, тәкъдимнәр һәм искәрмәләрне, Иске Абдул авылы, Үзәк урамы, 8 йорт, (Иске Абдул авыл җирлеге бинасы) эш көннәрендә-8.00 дән 16.00 сәгатькә кадәр) бирергә кирәк

3.5.Ачык тыңлауларда катнашу хокукы белән гаризаларны бирү вакыты: 2019 елның 05 сентяберенә кадәр.

4.Тукай муниципаль районы Иске Абдул авыл җирлеге башкарма комитетына «Тукай муниципаль районы Иске Абдул авыл җирлеге бюджетының 2019 елның

беренче яртыеллыгы өчен үтәлеше турында хисап» карар проекты буенча ачык тыңлауларны бирелгән вакытта әзерләргә һәм үткәрергә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуын үз өстемә алам.

Иске Абдул авыл җирлеге Башлыгы Р.Х.Сафина